*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре**
**2023-2024 нче уку елы**
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 58**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Җөмләдәге рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Менә бервакыт, агач яфракларын учы белән сыпырып, җил узып китә. (Ф.Яруллин)*
1) бервакыт
2) яфракларын
3) сыпырып
4) китә

2. Әйтелеше белән язылышы туры килмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) чишмә
2) тәэсир
3) хәтер
4) багланыш

3. Кушылып языла торган сүзне билгеләгез. (**2 балл**)
1) бил бау
2) аллы гөлле
3) миләш чыпчыгы
4) рәхим шәфкать

4. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Чәч толымына кушып үрә торган бауга яки тасмага таккан тәңкәләр*
1) изү
2) алка
3) чулпы
4) чәчүргеч

5. Җөмләдәге алынма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Никадәр шигырь, күпме роман язылган икмәк турында! (Н.Дәүли)*
1) күпме

2) шигырь
3) язылган
4) икмәк

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Сүз күп җирдә*
1) эш гөрләп бара.
2) бар да эшчән.
3) кешегә урын юк.
4) эш аз була.

7. Җөмләдәге тезмә сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Кинәт мәче башлы ябалак ук кебек аска томырыла. (М.Закиров)*
1) аска томырыла
2) мәче башлы ябалак
3) ук кебек
4) кинәт томырыла

8. Җөмләдәге тартым белән төрләнгән исемнең килешен билгеләгез. **(2 балл)**
*Кинәт каядыр колагына серле аваз чалынгандай булды. (Р.Мөхәммәдиев)*
1) юнәлеш
2) төшем
3) чыгыш
4) иялек

9. Ике составлы җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Ишек шакыйлар.
2) Төн. Караңгылык.
3) Арытты.
4) Балалар укыйлар.

10. Җөмләдәге нокталар урынына тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**
*Су буйлап сузылган авыл урамын кисеп чыгуга ... дуслар Сары тауга күтәрелә башладылар.*

Җавап: ____________

**II. Теоретик бирем.**

Затланышлы фигыльләр турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**6 балл)**

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Рәвешләр һәм аларның төркемчәләрен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) түбән | 1) охшату-чагыштыру рәвеше |
| Ә) әкрен | 2) вакыт рәвеше |
| Б) әрәмгә | 3) урын рәвеше |
| В) инглизчә | 4) сәбәп-максат рәвеше |
| Г) тиздән | 5) саф рәвеш |

**Җавап : ________________________**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(5 балл)**

Март ахыры (килгәч / якынлашкач / беткәч), беренче зур яңалык шул булды: кычыткан күбәләге оча башлады. Кирпеч төсле кызыл күбәләк. Шул кызыл өстендә вак кара таплар күренә. Юка канатлары читеннән кара кайма киткән, ә каймага зәңгәр таплар (куелган / тезелгән / бизәнгән). Күбәләк суыкны агач ярыгында уздырган һәм яз җиткәч уянган.

Бераздан үрмәкүчләр (уянды / торды / килде), кайберләре кар өстендә сәяхәт итә башлады. Иртән кояш күренә – үрмәкүч (чыга / терелә / күренә), кичен суыта – ул тагы үлеп куя. Бу төр үрмәкүчләрне сукбай дип йөртәләр, чөнки алар бөҗәкләрне (баусыз / җәтмәсез / җепсез) аулыйлар. (*Г. Хәсәновтан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Уйнар идем, гармуным юк,
Җырлар идем – та...ышым.
Кисеп алып курай ит...ем
Елгабызның камышын.
Камыш курай эчләрендә
Күпме м...ң булган икән!
Ул камышка җәйләр буе
Күпме кош ку...ган икән? (*Ф. Яруллин*)

3. Тойгылы җөмләне күчереп языгыз. (**2 балл)**

______________________________________________________________

______________________________________________________________

4. *Елгабызның* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерып языгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**4 балл**)

________________________________________________________________

5. *Кош* сүзенә 2 тамырдаш сүз уйлап языгыз. **(2 балл)**

________________________________________________________________

6.  Шигырьдән алынма сүзне күчереп языгыз. **(2 балл)**

______________________________________________________________

7.“*Минем хыялым*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)